ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» Татарстан Республикасы Законының 4 һәм 12 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2019 елның 22 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» 2005 елның 1 апрелендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (2015 елның 2 июлендәге 51-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 4 (I өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 38 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2019, № 19 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяның 2 өлешенә түбәндәге эчтәлекле $9^7$ пункт өстәргә:
«$9^7$) тарихи-мәдәни музей-тыюлыклар һәм музей комплекслары территорияләре чикләрендә урнашкан мәдәни мирас объектларын ансамбльләргә яисә истәлекле урыннарга кертү, Россия Федерациясе Хөкүмәте раслаган федераль әһәмияттәге аерым мәдәни мирас объектлары исемлегенә кертелмәгән федераль әһәмияттәге мәдәни мирас объектларының объектлар составын билгеләү;»;

2) 12 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«12 статья. **Мәдәни мирас объектларында мәгълүмати язмалар һәм билгеләр**

1. Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни ядкарьләренең) бердәм дәүләт реестрына кертелгән мәдәни мирас объектларында мәдәни мирас объекты турында мәгълүмат булган язмалар һәм

билгеләр (алга таба – мәгълүмати язмалар һәм билгеләр) урнаштырылырга тиеш. Мәгълүмати язмалар Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә эшләнгән булырга тиеш.

Ачыкланган мәдәни мирас объектларына, археологик мирас объектларына, истәлекле урыннарга, шулай ук аерым каберлекләр, некропольләр булып торучы мәдәни мирас объектларына мәгълүмати язмалар һәм билгеләр урнаштырылмый.

2. Мәдәни мирас объектларына мәгълүмати язмалар һәм билгеләр урнаштыру тәртибе, әлеге мәгълүмати язмалар һәм билгеләрнең эчтәлеге, шулай ук мәгълүмати язмалар һәм билгеләрне урнаштыру өчен нигез була торган мәгълүмати язмалар һәм билгеләр урнаштыру һәм аларның торышын тикшереп тору проектлары составына карата таләпләр Федераль закон нигезендә Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә.

3. Мәгълүмати язмалар һәм билгеләрне урнаштыру түбәндәгечә гамәлгә ашырыла:

1) мәгълүмати язмалар һәм билгеләрне урнаштыру Федераль закон нигезендә башка затлар тарафыннан гамәлгә ашырыла торган очраклардан тыш, Татарстан Республикасы милкендәге мәдәни мирас объектларына – Татарстан Республикасы мөлкәте милекчесе вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы тарафыннан;

2) Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан исемлеге билгеләнә торган федераль әһәмияттәге аерым мәдәни мирас объектларыннан тыш, милекчеләре булмаган яисә милекчеләре билгесез булган, яисә милекчеләре милек хокукыннан баш тарткан мәдәни мирас объектларына – Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау органы тарафыннан.».

**2 статья**

1. Тарихи-мәдәни музей-тыюлыклар һәм музей комплекслары территорияләре чикләрендә урнашкан Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни ядкарьләрен) ансамбльләргә яисә истәлекле урыннарга кертү, ансамбльләрнең яисә истәлекле урыннарның объектлар составын билгеләү Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау органы тарафыннан 2025 елның 1 гыйнварына кадәр башкарыла.

2. Әгәр тарихи-мәдәни музей-тыюлыклар һәм музей комплекслары территорияләре чикләрендә урнашкан ансамбльләрнең яисә истәлекле урыннарның төрләре һәм (яисә) объектлары составы турында белешмәләр «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкарьләре) турында» 2019 елның 21 февралендәге 11-ФЗ номерлы Федераль закон үз көченә кергән көнгә Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни ядкарьләренең) бердәм дәүләт реестрына кертелгән булса, мондый ансамбльләрнең яисә истәлекле урыннарның төрләрен һәм (яисә) объектлары составын билгеләү буенча чаралар үткәрелми.

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2019 ел, 29 апрель
№ 36-ТРЗ